ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
(IV чакырылыш)

**IV чакырылыш чираттан тыш утырыш**
**КАРАРЫ**

**№ 13 Әбсәләм ав. 16 июнь 2025 ел**

**Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»гы Федераль законның 10 маддәсендәге 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 маддәсендәге 2 өлеше, 105 маддәсендәге 1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 17 маддәсенә ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге Советы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының бишенче чакырылыш Әбсәләм авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Ютазы таңы» («Ютазинская новь») газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга. http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә дип билгеләргә.

Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В.Кубашева